ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 05 2019 г. № 125

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 19 октябрендәге 1064 номерлы карары нигезендә, һәм Балтач муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенең халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә 2019 елның 28 мартындагы 7 номерлы Протоколы нигезендә үтәлеше турында тыңлау беркетмәсе нигезендә, Балтач муниципаль район башлыгы **карар бирә**:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Балтач звеносы турындагы 2018 елның 10 мартындагы 56 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (25.09.2018 №159 номерлы ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең «10» пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

10.1 Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекчәсе көчләре һәм чаралары хәрби исәп хисап нигезендә кулланыла:

- районда гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен тәэмин итәләр;
- торак пунктларда массакүләм тәртипсезлекләрне кисәтү;
- авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрүдә катнашу, янгыннарга каршы көрәш;
- оператив-эзләү чараларында катнашу.

2.Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе Хайрутдинов А. Ф. йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы Р.Р.Нотфуллин